| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2024 г.Казань № 513-70/тэ-2024

Алабуга муниципаль районы «Комплексное энергоразвитие - Генерация» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2025 елга тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитетының «2028 елга кадәр Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 24.03.2023 ел, №357 карары, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 16.12.2024 ел, №33-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы «Комплексное энергоразвитие - Генерация» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән (алга таба – «КЭР-Генерация» ҖЧҖ) җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә), әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2024 № 513-70/тэ-2024
карарына кушымта

«КЭР – Генерация» ҖЧҖ җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2025 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | басым астында сайланма пар | | | | кискен һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Алабуга муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «КЭР – Генерация» ҖЧҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 1 053,84 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 1 226,54 | - | - | - | - | - |

Искәрмә. 1 Гкал җылылык энергиясенә кертелгән, «КЭР-Генерация» ҖЧҖ җылылык энергиясе чыганагыннан су рәвешендә җибәрелә торган ягулыкка чыгым зурлыклары:

сум/Гкал

| т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Ел | Су | басым астында сайланма пар | | | | кискен һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | «КЭР – Генерация» ҖЧҖ | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 632,29 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 755,95 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге